Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

**18 декабрь 2020 ел** **№ 152**

**Арча шәһәр муниципаль
берәмлегендә гражданнарының үзара
салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча шәһәр муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда кабул ителгән 2020 елның 7 нче декабрендәге 596 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Арча шәһәр башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча шәһәр муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокурый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгарырга, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм: Арча шәһәр башкарма комитеты бинасы (Арча ш., Совет мәйданы, 27); район мәдәният йорты (Арча ш., Совет мэйданы, 24); КФҮ (Арча ш., Х.Такташ ур., 58); совхоз клубы (Арск ш., Өрәңгеле ур., 4); узәк китапханә (Арча ш.,Банк ур.,2а) адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Арча шәһәр Башкарма комитетының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында 2018 елның 22 ноябрендәге 237 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәр муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

**Арча шәһәр башкарма
комитеты җитәкчесе** **Р.Ф. Касыймов**

Арча шәһәр
башкарма
комитетының 2020
елның 18 нче
декабрендәге
152 нче номерлы
карарына 1 нче
кушымта

**Арча шәһәр муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча шәһәр муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Үзара салым акчасы 18 яшькә җиткән һәм Арча шәһәр муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, җирле референдумда катнашу-катнашмауга, тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2021 елның 6 нчы мартына кадәр түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) 1 нче төркем инвалидлар,

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар,

в) Бөек Ватан сугышы ветераннары,

түләү күләме җирле референдум карарында билгеләнгән сумманың 33 ( утыз өч) процентын тәшкил итә.

4. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (эти-әнисе, тормыш иптәше, балалары) үлеме,

б) янгыннан һәм бәлә-казадан зыян күрү,

өч айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгару, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм: Арча шәһәр башкарма комитеты бинасы (Арча ш., Совет мәйданы, 27); район мәдәният йорты (Арча ш., Совет мэйданы, 24); КФҮ (Арча ш., Х.Такташ ур., 58); совхоз клубы (Арск ш., Өрәңгеле ур., 4); үзәк китапханә (Арча ш.,Банк ур., 2а) адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълумат такталарына урнаштыру, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша халыкка җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Арча шәһәр муниципаль берәмлеге шәхси хисабына күчерелә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыруга һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Билгеләнгән вакытта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Арча шәһәр
башкарма
комитетының 2020
елның 152нче № лы
карарына 2 нче
кушымта

Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү
турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.И.
________________________________________________
Адресы:_________________________________________
Нигезләмә:______________________________________
Сезгә ______________________ кадәрге вакыт эчендә ______________________________ чараны гамәлгә ашыру буенча ____________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК __**049205001**__________________
Сч. № __
Кабул итеп алучы Сч. № **40101810800000010001**____________
ИНН ____**1609009548**
КПП ____**160901001**_________________________
КБК __**89511714030 13 0000 150**
ОКАТО **92612151**
Түләүнең билгеләнеше_____________________________
Җитәкче _______________ _________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

--------------------- -- **кисеп алу сызыгы** -----------------

Арча шәһәр муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне ________________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.И.
________________________________________________
Адресы:_________________________________________
Кабул ителде «__» ___________ 20__ ел. ____________________
(түләүченең имзасы/ фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Арча шәһәр җирлеге башкарма комитетында кала.*